ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.Г. Хәбибуллин, Л.А. Якунин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» 80-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 304-VII ДС

Проект

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.Г. Хәбибуллин,
Л.А. Якунин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (I өлеш); 2005, № 5; 2007, № 5; 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 3; 2014, № 5, № 11 (I өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 1 – 2; 2016, № 1 – 2, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 73 (I өлеш), 2024, № 44 (I өлеш), № 93 (I өлеш),19 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Депутатка депутатлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә ай саен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратын тотуга билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы билгеләгән күләмдә түләүләр бирелә.».

**2 статья**

Әлеге закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары эшчәнлеген матди тәэмин итү тәртибен камилләштерү максатыннан эшләнде.

Закон проектында депутатка депутатлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә бирелә торган түләүләр күләмен билгеләү вәкаләтен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумына йөкләү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә акчалар бүлеп бирүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 19 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яисә кабул итүне таләп итми.